| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**КАРАР**

**01 августа 2024** **№ 20**

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2016 елның 09 декабрендәге 42 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләрне гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алганнан соң түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт (Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы), Спиридоновка авылы, Совет ур., 32 йорт (мәдәният йорты бинасы); Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы, Совет рәисе

А.А.Потапов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 01 августындагы 20 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр

**1) 5 статьяда:**

**1 өлешнең 12 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12) Зеленая Роща авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 21 пункт** белән тулыландырырга:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

**2) 7 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

**3) 11 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында** «җирлек сайлау комиссиясе сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.»;

**4) 13 статьяда:**

**5 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясен» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга»;

**8 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**12 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**5) 27.1 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацында** «40 статьясындагы 10 өлешенең 1 - 7 пунктларында» сүзләрен «38 статьясындагы 1-7 һәм 10.1 пунктларында»сүзләренә алмаштырырга»;

**6) 28 статьяның 6 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

**7) 30 статьяның 1 өлешендә** «Җирлек сайлау комиссиясе « сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе»сүзләренә алмаштырырга»;

**8) 31 статьяда:**

**1 өлешнең 13 пунктын** үз көчен югалткан дип танырга;

**28 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

**9) 38 статьяның 1 өлешен** түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт белән тулыландырырга:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

**10) 41 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

**11) 44 статьяның 2 өлешен** түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

«6) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

**12) 47 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктының икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленая Роща авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**13) VII бүлек** үз көчен югалткан дип танырга;

**14) 65 статьяны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

**«65 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе**

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль берәмлегенең «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып тора:

1) тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында ФС77-60244 номерлы таныклык бирелгән 17.12.2013 Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә

күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында;

2) Лениногорск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштыру;

3) Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт (Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы), Спиридоновка авылы, Совет ур., 32 йорт (мәдәният йорты бинасы) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру».

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Лениногорск муниципаль районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль берәмлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә.».